| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ БОЕРЫК

2025 елның 28 апреле Алабуга шәһәре № 421

«2024 елгы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында»

«Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турында» Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 153, 264.6 статьяларына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елгы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны Алабуга муниципаль районы (алга таба - район бюджеты) керемнәр буенча 4 679 404,8 мең сум һәм чыгымнар буенча 4 120 402,4 мең сум күләмендә керемнәрнең чыгымнардан артып китүе белән 559 002,4 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәрен;

- әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча район бюджеты чыгымнарын;

- әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча район бюджеты чыгымнарын;

- әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен чыгымнар төрләре төркемнәренә, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләренә һәм бүлекчәләренә максатчан статьялар (Алабуга муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага кертелмәгән юнәлешләре) буенча бүлү;

- әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын;

- әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә район бюджетыннан җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертларны бүлү;

- әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертларны бүлү;

- әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә Алабуга муниципаль районының резерв фонды үтәлеше;

- әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә Алабуга муниципаль районының юл фондын үтәлеше.

2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасының 2024 елгы эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Комиссия рәисе урынбасары Г.П. Баганов